ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2022 елның 19 июле** **Чистай шәһәре** **№ 478**

Чистай муниципаль районы буенча
2022 елның III кварталына торакның
1 квадрат метр гомуми мәйданының
нормативы турында

«2020-2025 елларга Чистай муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» программасын гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «2022 елның икенче яртыеллыгына Россия Федерациясе буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрының нормативы һәм Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» 2022 елның 20 июнендәге 501/пр номерлы боерыгы, «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2022 елның 07 февралендәге 37 номерлы «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге» НП хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы буенча 2022 елның III кварталына торакның 1 квадрат метр (сумнарда) гомуми мәйданының нормативын 61 796 (алтмыш бер мең җиде йөз туксан алты) сум күләмендә расларга.
2. Чистай шәһәре Башкарма комитетының торак сәясәте бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru/) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары П.Б. Емельяновка йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р.Хәсәнов